РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ

КАРАР

№ 53

2022 елның 15 сентябре

**Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә иҗтимагый фикер алышулар һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 бүлектәге 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1 Халык яки Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советы инициативасы белән үткәрелә торган иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар район Советы тарафыннан Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы - район башлыгы инициативасы буенча, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча билгеләнә.»

8.1 бүлеген түбәндәге эчтәлекле 8.1.3 һәм 8.1.4 пунктлары белән тулыландырырга:

«8.1.3 Авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, бер яки берничә торак пункт территориясенә, аларның өлешләренә карата иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар генераль планга үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелә. Бу очракта иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар үткәрү вакыты бер айдан артык була алмый.

8.1.4 РФ Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясындагы 7.1 өлешендә күрсәтелгән очракта, генераль планга үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проект буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар үткәрү вакыты, муниципаль берәмлектә яшәүчеләргә мондый иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр ителгәннән соң, мондый иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә бастырылган көнгә кадәр муниципаль

бердәмлек уставы һәм (яки) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан да кимрәк һәм ике айдан да артык була алмый.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Башлык урынбасары А.В.Умников